
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№8
Апрель 2018 г.

## Без Тукайны беләбез, яратабыз, өйрәнәбез!



***Тукай – үзенең исеме һәм иҗаты белән татар әдәбияты тарихында урынны иң түрдән алган, әдәбият күгендә иң якты янган йолдыз. Ул калдырган әдәби мирас, андагы рухи байлык – милләтебез мактанычы, горурлыгы. Апрель - дөнья буйлап Тукай айлыгы. Шул уңайдан районыбызда безнең мәктәп укучылары да актив катнашкан бик күп чаралар уздырылды. Шулар турында кыскача:***

**VII Республикакүләм Габдулла Тукай укуларында** безнең мәктәптән: Зилә Фатыхова - II дәрәҗә, Рузаль Шәрипов лауреат дипломына (Җитәкчеләре-Ибраева Р.Х.); Гөлназ Байгубикова (Җитәкчесе-Фатыхова Л.Ә.) сертификатка лаек булды.



**Районкүләм “Туган тел – иң татлы тел” шигырь бәйгесендә** I дәрәҗә диплом белән 8Б сыйныфы укучысы Алия Хабирова (Җитәкчесе – Ибраева Р.Х.), II дәрәҗә диплом белән 5А сыйныфы укучысы Әмир Кондратьев, 6Б сыйныфы укучысы Алия Миннибаева һәм 10 сыйныф укучысы Аделина Аглиуллина,



III дәрәҗә диплом белән 6Б сыйныфы укучылары Арсений Манаков һәм Алсу Минһаҗева бүләкләнде Җитәкчеләре - Фатыхова Л.Ә. Җиңүчеләрне Котлыйбыз!

## Интересно знать!

- Некоторые гусеницы могут есть себя в отсутствии другой пищи.
- Деньги не сделаны из бумаги, они сделаны из хлопка.
- Венера - единственная планета, вращающаяся по часовой стрелке.
- Слоны - единственные млекопитающие, не умеющие прыгать и единственные животные с 4 коленями.
- У улитки около 25 тысяч зубов.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Тукай марафоны старт алды | 2 |
| ...Шушы туфрактан без! | 2 |
| “Моңлы сазым” бәйгесе | 3 |
| Сәләтлеләрне барлыйлар | 3 |
| Уңышларыбыз | 3 |
| Иң беренче КамАЗ машинасын күргән якташыбыз | 5 |
| Тукай энциклопедиясе | 6 |

# Тукай марафоны старт алды

***Тукай -27 ел гына яшәсә дә татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган. Ул калдырган әдәби мирас чыннан да татар халкының горурлыгы.***

Тукай татар әдәбияты тарихына яңа милли поэзиягә, заманча татар теленә нигез салучы буларак керде.

Габдулла Тукай кыска гына иҗат гомерендә 400дән күбрәк шигырь, 9 поэма, 350 хикәя, очерк һәм истәлекләр язып калдыра. Бөек талант иясе 20нче гасыр башы татар поэзиясен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә.

18нче апрель көнне мәктәбебездә район күләмендә “Тукай,Тукай синең моңны тыңлый туган халкым” исеме астында вокаль конкурсы уздырылды.



Конкурста 35 укучы көчен сынады. Вокал – җыр конкурсы буенча Никитина Зарина беренче дәрәҗәдәге лауреат дипломы белән бүләкләнде. Шушы ук номинациядә Габдрахманова Розалия Җинүче дипломы белән бүләкләнде.

Алсу Минһаҗева,Әмир Кондратьев конферансье номинациясендә икенче дәрәҗәдәге дипломга лаек булдылар. Алсу Минһаҗева икенче дәрәҗәдәге (үзе генә) дипломга; Асадуллин Нияз өченче дәрәҗәдәге дипломга ия булдылар.

Татар халкының сөекле шагыйре тормышы һәм иҗаты белән татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертә, аның йогынтысы бүгенге көндә дә дәвам итә.

**Эльмира ЗӘБИРОВА,**
туган тел укытучысы



# Шушы яктан – шушы туфрактан без!

Арча муниципаль районы Яңа Кенәр гомуми белем бирү мәктәбендә 13 апрельдә ***РСФСРның атказанган укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны Рәгыйб Усман улы Халитов*** исемендәге икенче районара һәм VI мәктәпкүләм "Шушы яктан, шушы туфрактан без" фәнни-гамәли конференциясе булып узды. 6 нчы сыйныф укучысы Алсу Минһаҗева уңышлы чыгыш ясады һәм катнашучы сертификаты белән бүләкләнде (Җитәкче-Фатыхова Л.Ә.).

# “Моңлы сазым” быел да Тукай иҗатын яратучыларны үзенә җыйды

***Арча шәһәренең Казан арты музеенда 26 нчы апрель көнне «Моңлы сазым» исемле әдәби–музыкаль кичә уздырылды. Бу бәйрәмгә Тукай иҗатын яратучы, җыр–моңга гашыйк, каләм тибрәтүче укучылар җыйналды.***

Әлеге чарадан безнең мәктәп укучылары да читтә калмады. “Тукай сүзләренә язылган җырларны башкаручы” номинациясендә 9 нчы А сыйныфы укучысы Никитина Зәринә чыгыш ясап,”Тәфтиләү”не җырлады.”

Укучыларның Тукайга багышлап язган шигъри әсәрләре” номинациясендә 6 нчы В сыйныфы укучысы Аюпова Алинә “Тукай безнең истә гел” исемле иҗат җимешен тәкъдим итте. (Җитәкчесе Г.Р. Мөбәрәкшина). «Тукай иҗаты – милли уен коралларында» - 9 нчы Асыйныфы укучысы Мостафин Дәниф баянда “Туган тел “ көен уйнады (Җитәкчесе Р.Б.Хәбирова).



«Тукайның шигъри әсәрләрен укучылар” арасында 10 нчы сыйныф укучысы Галиуллина Гүзәлгә тиңнәр булмады шикелле.” Җәйге таң хатирәсе” шигырен ул бөтен җаны-тәне аша уздырып, тамашачыга җиткерде (Җитәкчесе-Р.Х. Ибраева). Бәйрәм истәлеге итеп,һәр укучыга дипломнар тапшырылды.

**Гөлнара МӨБӘРӘКШИНА,**
туган тел укытучысы

# Уңышларыбыз

- Галимҗан Ибраһимовның тууына 131 ел тулу уңаеннан IX Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә катнашып, 9А сыйныфы укучысы Зәринә Сәләхова уңышлы чыгыш ясады (Җитәкчесе Мөбәракшина Г.Р.).
- Абдулла Алиш исемендәге V фәнни-гамәли конференциясе “Әкиятләрдән – олы тормышка” номинациясендә 6В сыйныфыннан Алинә Әюпова, Булат Гарипов катнашты (Җитәкчеләре Мөбәракшина Г.Р.).
- 8А сыйныфы укучысы Диана Гайфуллина “Тукай – халыкның үз баласы” район күләмендә узырылган инша бәйгесендә катнашты.

# Сәләтлеләрне барлыйлар

***24нче апрель көнне Сәләт Йортында Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» VII ачык әдәби конкурсының финалы узды.***

Безнең мәктәптән 8Б сыйныф укучысы Шәрипов Рүзәл “Балалар әдәбияты” номинациясендә III дәрәҗә, “Публицистика” номинациясендә II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

«Сәләткә нур булган йолдызлар» – үзеңне һәм үзеңнен сәләтләреңне ачар өчен менә дигән мөмкинлек, минемчә. Җиңүчеләрне котлау белән генә чикләнмичә, аларга Сәләт Йортында кызыклы мастер-классларлар үткәрелүе, җанлы аралашу, тәкъдимкиңәшләр бирелүе бик ошады. Конкурсның казыйлар Шурасы танылган шагыйрьләр, прозаиклар, күренекле журналистлардан торды. Иҗат җимешләрем мондый олуг шәхесләр тарафыннан бәяләнүе күңелемдә горурлык хисләре уятты.

**Рүзәл ШӘРИПОВ**



# Үз телеңне сакларга тырышырга кирәк...



***Галимнәр әйтүенчә, күренекле мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең кайбер кулъязмалары әле һаман да яхшылап өйрәнелмәгән. Хәтта Ташкичү авылында аларның бәрәңге бакчасында баз булган, Мәрҗани китаплары шунда ташылган, дигән гыйбарә дә йөри. Имеш бу турыда авылның бер әбисе сөйләп калдырган.***

Ачыкланмаган нәрсәләр күп. Тарихыбызда тирән эз калдырган Шиһабетдин Мәрҗанине, аның кулъязмаларын өйрәнергә дә өйрәнергә әле. Ташкичү мәктәбендә республика күләмендә галимнәр, дин әһелләре белән берлектә "Мәрҗани укулары"н үткәрү әнә шул максатны күздә тотып оештырылган. Анда Казаннан Г. Ибраһимов исемендәге тел һәм әдәбият институты галиме Фәрит Яхин, КФУ галимәсе Рәсимә Шәмсетдинова, Мәрҗанинең туганнары, шагыйрь Рөстәм Зәкуан, музей хезмәткәрләре, укытучылар, укучылар катнашты. Әлеге чараны район мәгариф идарәсе җитәкчесе Алмаз Ибраһимов ачып җибәрде. "Буыннарның бердәмлеге дәвам итәр", – дип ышандырды ул.

Ш. Мәрҗани мирасын өйрәнү 5 секциядә алып барылды. Мәртәбәле жюри алдында 77 укучының чыгышы тыңланды. II урын алган Арчаның 2нче мәктә-бенең 10 сыйныф укучысы Гөлфинә Җәләлиеваның бер-нәрсәдән карамыйча сөйләве, үз фикере булуы сокландыр-ды.

– Ш. Мәрҗани күп телләрне, күп фәннәрне белгән, татар ханнарын барлаган, – дип сөйләде Гөлфинә. – Шиһабетдин хәзрәт музыка кешене тынычландыра, анда үзеңә таяныч табасың, дип музыканы таныган. Мәрҗанине югары сыйныфка җиткәч кенә түгел, кечерәк сыйныфларда да өйрәнергә кирәк.

Ш. Мәрҗани укуларының йомгаклау өлеше Ташкичү мәдәният йортында булды. Укучыларның хезмәтләренә бәя бирелеп, бүләкләр тапшырылды.

Язмамны Шиһабетдин Мәрҗанинең тел турындагы сүзләре белән тәмамлыйсы килә. Мәгърифәтче,…мөмкин кадәр үз телеңне сакларга тырышырга кирәк, дигән.

***arskmedia.ru***
*сайтыннан алынды*

# Премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев белән очрашу

***19нчы апрель көнне Васил Шәйхразиев "Лидерлар мәктәбе" проекты кысаларында балалар басмасының активистлары, штаттан тыш хәбәрчеләре белән очрашты. Очрашу Татарстан Министрлар Кабинетында узды.***

"Лидерлар мәктәбе" - "Ялкын" журналы тарафыннан инде шактый еллар элек башланган һәм узган елда яңа баш мөхәррир килү белән кабат яңартылган проект.



Очрашуга "Ялкын"ның яшь корреспондентлары республиканың төрле районнарыннан килгән иде. Алар - сәләтле, укуда да тырыш, иҗтимагый тормышта да актив булган 6 укучы. Шулар арасында безнең мәктәптән 8нче сыйныф укучысы Рүзәл Шәрипов та бар иде. Һәркайсының үз максатлары, хыяллары бар. Аларның әле күбесе киләчәктә үзләренең журналист булачакмы-юкмы икәнлекләрен төгәл белми, шулай да бүген алар үзләрен шушы һөнәрдә сыный. Бу исә алар тормышында билгеле бер тәҗрибә булачак.

# Иң беренче КамАЗ машинасын күргән якташыбыз



***Дөньякүләм Ралли ярышларының популярлыгы көннән-көн арта бара. Заманча КамАЗлар ярышканын кем генә яратып карамый икән?***

Вакытлы матбугат биотләреннән әлеге спорт төре турындагы язмаларны мин дә укыйм. Ә менә Равил Вәли улының КамАЗлар белән "җенләнеп" язган мәкаләләрен бер дә укыганым булмады. Тукай укулары миңа якташым турында белергә ярдәм итте. Әдәбият-сәнгать музеенда сакланган мәгълүматлар аша мин аның журналист буларак иң беренче КамАЗ машинасын тәкъдир итү тантанасында катнашканын белдем. Равил Вәлинең Тукай исемен йөрткән педагогия көллиятендә белем алганын белгәч, кызыксынуым тагын да арта төште.



Язучы һәм публицист Равил Вәли улы Вәлиев 1942 нче елның 20 нче августында Арча районы Яңа Кенәр авылында туа. 1960 нчы елны Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлап, Арча педагогия училищесына укырга керә. 1961-1964 нче елларда хәрби хезмәттә була. Армиядән кайткач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый.

1969 нчы елда университетны тәмамлагач, Чаллы шәһәренә китә. Шәһәрнең төзелеш оешмаларында ташчы, күп тиражлы газеталарда баш мөхәррир урынбасары, ремонтлау-инструментлар заводында матбугат үзәге җитәкчесе, шәһәр радиотапшырулар үзәгендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

1973 нче елда беренче китабы – "Шәһәр булсын йөрәгем" исемле документаль повесте басылып чыга, 1978 нче елда "Таяну ноктасы", 1983 нче елда "Көчле агым", китапрлары дөнья күрә. Беренче иҗат җимешләрен һәм Чаллы каласының җәмгыять эшләрендә актив катнашуын искә алып, 1978 нче елда Равил Вәли "КамАЗ төзелеше ударнигы" дигән мактаулы исемгә лаек була.

Әтием Фәнис миңа ул елларда барлык малайларның КамАЗ машиналары белән кызыксынганын, шуларны ясауда катнашырга хыялланып үскәннәрен сөйләде.

2002 нче елда "Җөй" һәм 2005 нче елда "Олуг хан ярлыгы" китаплары басылып чыга.

Ул 1978 нче елдан Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы, "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре", Татарстан Язучылар берлегенең Фатыйх Хөсни исемендәге премия лауреаты.

Бүгенге көндә ул гаиләсе белән Казан шәһәрендә яши һәм иҗатын дәвам итә.

**Рүзәл ШӘРИПОВ**,
8 нче сыйныф

# Тукай энциклопедиясе

***Быел без бөек Тукаебызның 132 еллыгын билгеләп үтәбез. Бөек шагыйребез җәүһәрләре республикабыз исемен дөньякүләм ишеттерүдә, татар милләтен танытуда зур әһәмияткә ия.***

Татар телендә беренче шәхси энциклопедия - Тукай энциклопедиясе басылып чыгу — Татарстанның мәдәни тормышында истә калырлык зур бер вакыйга.

Проект киң катлау укучыларга юнәлдерелгән. Ул шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән чорны, анын тирәлеген, әсәрләрен аңлауда булышлык итәрлек хезмәт. Энциклопедияне төзүдә катнашкан Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре 24 апрель көнне Өчиле төп гомуми белем мәктәбенә китапны тәкъдим итәргә кайттылар.



Галимнәр укучыларны, укытучыларны энциклопедия чыгару тарихы, бүлекләре, мәкаләләр белән таныштырдылар, аларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирделәр.

2,5 кг авырлыктагы, 864 биттән торган бу энциклопедия 2358 фәнни-нәзари мәкалә һәм белешмәне үз эченә ала. Алар бүгенге кулланылыштагы татар алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Һәр мәкалә азагында әсәрләр һәм әдәбият исемлеге бирелгән. Исемлектә мәкалә, белешмәнең темасы чагылыш тапкан төп чыганаклар күз алдында тотыла. Гарәп яисә латин графикасындагы татар телле чыганаклар барысы да кирилл язуында китерелә. Китапта Тукай дөньясы 8 тематик юнәлештә тәкъдим ителә.

Галимнәр шулай ук “Тукай альбомы “ белән дә таныштырдылар, фотосурәтләргә аңлатмалар бирделәр. Кичә бәйрәм рухында шигырьләр,моңлы җырлар, дәртле биюләр белән үрелеп барды.

Шунысы шатлыклы, Тукай энциклопедиясе районыбыздагы һәр мәктәпкә бүләк ителде.Тукайның мәңге яшәр иҗаты безне алга таба да изге эшләргә һәм игелекле гамәлләр кылуга рухландырыр, юл күрсәтүче маяк булып балкыр!

**Лилия ФАТЫХОВА,**
туган тел укытучысы



*Георгиевская лента – и порох, и огонь –*
*И скорбь души, и солнце жизни новой.*
*Узор двухцветных линий – истории ладонь,*
*Судьбы орнамент... Памятное слово…*

***Носите Георгиевские ленты только на левой стороне груди! Это лучший способ проявить уважение к людям, отдавшим свою жизнь за будущее нашей страны.***

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов
***Фотокорреспондент*** Диана Галимова
***Корректор*** Данил Степанов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Гузель Насибуллина
Инсаф Насибуллин
***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2